БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 11 2024 ел № 286

2025 елга социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләренә һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләренә торак урыннан файдаланган өчен, торак урынны карап токтан өчен түләү күләмен раслау турында, торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәүчеләр өчен түләү күләмен раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Балтач район Советының 2007 елның 19 ноябрендәге «Балтач муниципаль районы коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифларны җайга салу тәртибе турында» 91 номерлы карарына яраклы рәвештә һәм Балтач муниципаль районы белән Балтач муниципаль районы җирлекләре арасында төзелгән килешүләр нигезендә Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе карар бирә:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр билгеләргә:

- социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләренә һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләренә торак урыннан файдаланган өчен, торак урынны карап токтан өчен түләү күләмен раслау турында, торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәүчеләр өчен түләү күләмен 1 нче кушымта нигезендә;

2. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.С.Галимуллин

Кушымта

| № п/п | Түләү исеме | Хезмәтне күрсәтү берәмлеге | Хезмәт күрсәтү берәмлеге өчен Тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2025 елның 1 гыйнварыннан 30 июненә кадәр | 2025 елның 1 июленнән 31 декабренә кадәр |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | Торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры | 4,30 | 4,91 |
| 2 | Йорт яны территориясен җыештыру | Торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры, аена | 7,23 | 7,23 |
| 3 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау | Торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры, аена | 3,00 | 3,00 |
| 4 | Йорт эчендәге сүүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры | 3,72 | 3,72 |
| 5 | Йорт эчендәге җылыту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры, айга | 1,00 | 1,00 |
| 6 | Йорт эчендәге электр белән тәэмин итү челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры,аена | 1,17 | 1,33 |
| 7 | Йорт эчендәге газ челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры, аена | 0,42 | 0,42 |
| 8 | Йорт эчендәге вентиляция каналларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры, аена | 1,55 | 1,55 |
| 9 | Йорт эчендәге төтен чыгару юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры, айга | 0,50 | 0,50 |
| 10 | Дезинсекцияләү | Торак урынның гомуми мәйданының | 0,25 | 0,25 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | квадрат метры, аена | | |
| 11 | Дератизацияләү | Торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры, айга | 0,28 | 0,28 |
| 12 | Контейнер мәйданчыкларын карап тоту | торак урынның гомуми мәйданының квадрат метры, | 0,35 | 0,35 |